МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
«ПАЛАТА ИМУЩЕСТВЕННЫХ И ЗЕМЕЛЬНЫХ ОТНОШЕНИЙ»
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Полковая ул., 9, с. Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422701

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
«МИЛЕК ҺӘМ ҖИР МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ПАЛАТАСЫ»
МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА
УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
Полковая урамы, 9, Биектау поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422701

Тел.: +7 (84365) 3-28-54, e-mail: pizobiektau@mail.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**14 октябрь, 2025 ел** **№ 1463-р**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының «Территориядә җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 21 сентябрендәге 1032-р боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Җир кодексының 11.10 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Пространстволы мәгълүматларның милли системасы» Бердәм цифрлы платформасы» Федераль дәүләт географик мәгълүмат системасы турында» 2022 елның 07 июнендәге 1040 номерлы карары нигезендә

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының 2021 елның 21 сентябрендәге 1032-р боерыгы белән расланган Территориядә җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлекнең 2.5.1 пунктындагы 6 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«6) әгәр сорала торган җир кишәрлеген төзү алда торганда һәм мондый җир кишәрлеге төзелергә тиешле территорияне ызанлау проекты булмаган очракта, территория чикләренең характерлы нокталары координаталарын күрсәтеп, җир кишәрлеген урнаштыру схемасы. Җир кишәрлеген урнаштыру схемасы xml форматында яисә Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын әзерләүгә һәм территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын электрон документ рәвешендә әзерләгәндә, территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләренең урнаштыру схемасы форматына карата таләпләрне раслау, аны әзерләү кәгазь чыганактагы документ рәвешендә гамәлгә ашырыла торган территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасы формалары» 2022 елның 19 апрелендәге П/0148 боерыгында каралган башка форматларда электрон документ рәвешендә бирелә.

Җир кишәрлеген урнаштыру схемасын электрон документ рәвешендә әзерләү пространстволы мәгълүматларның милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган Федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырылырга мөмкин.».

1.2. 3.5.4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.5.4. Регламентның 3.5.3. пунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.5.3 пунктында күрсәтелгән, шул исәптән пространство мәгълүматларыннан файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространстволы мәгълүматлар милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.

Регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны башкаруның максималь срогы бер эш көнен тәшкил итә.».

1.3. 3.6. статьяны түбәндәге эчтәлекле 3.6.3 пункт белән тулыландырырга:

«3.6.3. Регламентның 3.6.1 – 3.6.2 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.6.1 - 3.6.3 пунктында күрсәтелгән, шул исәптән пространство мәгълүматларыннан файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространстволы мәгълүматлар милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.

Регламент пунктында күрсәтелгән административ процедураларны башкаруның максималь срогы 20 эш көне тәшкил итә, алга таба җир кишәрлеген бирү турында хәбәр басылып чыккан очракта - 49 эш көне.».

2. Әлеге боерыкны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып игълан итәргә.

Рәис вазыйфаларын башкаручы А.Р. Хәсәнов